КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 22 июль г.Казань № 542

Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе эшчәнлегенә һәм аның 1983 – 2004 еллардагы генераль директоры А.Ф.Павловка багышланган скульптур-архитектура ансамблен Казан шәһәренең Авиатөзелеш районындагы А.Ф.Павлов исемендәге мәйданда урнаштыру турында

1983 – 2004 елларда Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе генераль директоры Павлов Александр Филиппович истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының һәм “Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе” акционерлык җәмгыятенең Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе эшчәнлегенә һәм аның 1983 – 2004 еллардагы генераль директоры А.Ф.Павловка багышланган скульптур-архитектура ансамблен Казан шәһәренең Авиатөзелеш районындагы А.Ф.Павлов исемендәге мәйданда урнаштыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе эшчәнлегенә һәм аның 1983 – 2004 еллардагы генераль директоры А.Ф.Павловка багышланган скульптура-архитектура ансамбленең баланс тотучысын билгеләргә тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин